ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2021 елның 22 ноябре № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә Чертуш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, моннан тыш, көндезге уку формасында укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче 1 төркем инвалидларыннан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны Чертуш авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материал сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), Яшьләр, Сөембикә урамнары буенча;
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, МТЗ-320 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу);
- зират территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, коры агачларны кисү, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылы мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// novosheshminsk. tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка танытырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов